Каюмов, Р. Нияз Акмалны искә алдылар: [Чаллы үзәк китапханәсендә Нияз Акмалның 70 еллыгы уңаеннан әдәби чара узды] / Р. Каюмов // Мәдәни җомга. – 2024. – №9 (7 март). – Б. 3.

# Нияз Акмалны искә алдылар

Чаллы үзәк китапханәсендә шагыйрь, язучы, журналист Нияз Акмалның 70 еллыгы уңаеннан әдәби чара узды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Илсөяр Иксанова, «Мәдәни җомга» газетасы баш мөхәррире Вахит Имамов, «Безнең мирас» журналы баш мөхәррире Ләбиб Лерон, «Казан утлары» журналы баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин һ.б. иҗат әһелләре катнашты.

Әдәби чараны И.Иксанова ачып җибәрде. «Татарстан Язучылар берлегендә торган бик күп язучылар Н.Акмал белән аралашып яшәде. Хәзер инде яшь буын килә. Алар Ниязның әсәрләрен укып үсте, шигърияте белән тәрбияләнде», – диде ул.

И.Иксанова Н.Акмалны үз тормышында, иҗат биографиясендә иң зур рольләрнең берсен уйнаган шәхес, дип атады һәм язучы белән танышу тарихын сөйләде. «1977 елда ул мине Лаеш районының Татар Сараланы авылы мәктәбеннән эзләп табып, иҗат канатлары куйды. Моның өчен мин Нияз абыйга чиксез рәхмәтле. Университетка укырга кергәндә мин аның бөтен шигырьләрен яттан белә идем».

Л.Лерон да Н.Акмал турында җылы хатирәләре белән уртаклашты. «Нияз абый йөрәге белән тоеп язучы шагыйрьләр рәтенә керә. Ул милләт язмышы, халыкның үткәне, киләчәге өчен борчылып яшәгән шагыйрь. Ул вазгыятьне тойган, йөрәгеннән кайнап чыккан шигырьләр язды. Ул күпкырлы шәхес иде. Беренче чиратта, мин аны яхшы журналист буларак таныйм. Заманында мин анда практика үттем. Миңа «Яшь Ленинчы»да беренче биремнәрне ул биргән иде. Аның хәтер мөмкинлеге мине таң калдырды. Ул Кадыйр Сибгатуллин, Саҗидә Сөләйманова, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмнең бөтен шигырьләрен диярлек яттан белә иде».

В.Имамов Н.Акмал белән яшьтәшләр, яшь аермасы 1 ай булганын әйтте. Ул икесе бергә эшләгән чорны искә алды. «Без университетта укыганда ук таныштык. Балык Бистәсе районы газетасында берничә ай бергә эшләргә насыйп булды. Аның ничек янып йөргәнен, ярыша-ярыша эшләгәнен беләм. Хәзер андый редакцияләр дә, андый журналистлар да юк. Без Нияз белән Балык Бистәсендә Кадыйр Сибгатуллинның шәкертләре булуыбыз белән бәхетле идек. Ни үкенеч, Кадыйр абый 52 яшендә, Нияз 53 яшендә китеп барды. Алар эталон кебек талантлы шагыйрьләр иде. Аларның яшьли китүе әдәбият өчен зур югалту булды. Кадыйр абыйны да, Ниязны да бик сагынам. Алар һәрвакыт минем күңелдә», – диде В.Имамов.

**Рифат КАЮМОВ.**